**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Ялаур ав. КАРАР

«14» октябрь 2025 ел № 3

Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Сосновка, Кирпичное авылларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Ялаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 26 октябрендә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге Сосновка авылы Үзәк урам, 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында, Үзәк урам буенча 1-27 йортлардан, Кирпичное авылы Тынычлык урамы буенча 3-15 йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Сосновка, Кирпичное авылларында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.
3. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Сосновка һәм Кирпечное авылларында яшәүче гражданнар өчен тәэмин ителә.

4 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлегенең Сосновка авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан республикасы
Нурлат муниципаль районы
Ялаур авыл җирлеге  башлыгы                                        П.В.Сандиряков